**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**
**РЕШЕНИЕ**

Зур Сукаеш авылы № 22 «03» сентябрь 2018 ел

Референдум уздыруны инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

"2019 елда Сукаеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү өчен Сез ризамы?:

торак пунктлар чикләрендә беренчел иминлек чараларын тәэмин итүне;

2) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыруны;

3) җирлек территориясен төзекләндерүне;

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы түбәндәге адрес буенча урнашкан Сукаеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Зур Сукаеш авылы., Совет ур., 30, ТР, Азнакай муниципаль районы, Банки-Сукаеш авылы, Үзәк ур., 56А; ТР, Азнакай муниципаль районы, Түбән Сукаеш авылы, Кызыл юл ур., 32

- түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы: http://pravo.tatarstan.ru, адресы буенча

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге веб-адрес буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис Закирова З.Җ.